**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлегенең Кыят авылында гражданнар җыены карары**

19 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлегенең Кыят авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Кыят авыл җирлегенең Кыят авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Кыят авылында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын урнаштыру).

3. Җыен нәтиҗәләрен Кыят авыл җирлегенең Кыят авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кыят авыл җирлеге башлыгы _________ А.Н.Мишин

Гражданнар җыены секретаре _________ Р.З.Фәйзуллова